## Июнь аенда кояш чыгу, кояш бату һәм намаз уку вакытлары

| Көннәр | Иртәнге намаз | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Кояш бата Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2.48 | 4.18 | 13.05 | 18.14 | 20.59 | 22.29 |
| 2 | 2.48 | 4.18 | 13.05 | 18.14 | 21.00 | 22.30 |
| 3 | 2.47 | 4.17 | 13.05 | 18.15 | 21.01 | 22.31 |
| 4 | 2.46 | 4.16 | 13.05 | 18.16 | 21.03 | 22.33 |
| 5 | 2.45 | 4.15 | 13.05 | 18.16 | 21.04 | 22.34 |
| 6 | 2.45 | 4.15 | 13.05 | 18.17 | 21.05 | 22.35 |
| 7 | 2.44 | 4.14 | 13.05 | 18.18 | 21.06 | 22.36 |
| 8 | 2.43 | 4.13 | 13.05 | 18.18 | 21.06 | 22.36 |
| 9 | 2.43 | 4.13 | 13.05 | 18.19 | 21.07 | 22.37 |
| 10 | 2.42 | 4.12 | 13.05 | 18.19 | 21.08 | 22.38 |
| 11 | 2.42 | 4.12 | 13.05 | 18.20 | 21.09 | 22.39 |
| 12 | 2.42 | 4.12 | 13.05 | 18.20 | 21.10 | 22.40 |
| 13 | 2.41 | 4.11 | 13.05 | 18.21 | 21.10 | 22.40 |
| 14 | 2.41 | 4.11 | 13.05 | 18.21 | 21.11 | 22.41 |
| 15 | 2.41 | 4.11 | 13.05 | 18.21 | 21.12 | 22.42 |
| 16 | 2.41 | 4.11 | 13.05 | 18.22 | 21.12 | 22.42 |
| 17 | 2.41 | 4.11 | 13.05 | 18.22 | 21.13 | 22.43 |
| 18 | 2.41 | 4.11 | 13.05 | 18.22 | 21.13 | 22.43 |
| 19 | 2.41 | 4.11 | 13.05 | 18.23 | 21.13 | 22.43 |
| 20 | 2.41 | 4.11 | 13.05 | 18.23 | 21.14 | 22.44 |
| 21 | 2.41 | 4.11 | 13.05 | 18.23 | 21.14 | 22.44 |
| 22 | 2.41 | 4.11 | 13.05 | 18.23 | 21.14 | 22.44 |
| 23 | 2.41 | 4.11 | 13.05 | 18.23 | 21.14 | 22.44 |
| 24 | 2.42 | 4.12 | 13.05 | 18.24 | 21.14 | 22.44 |
| 25 | 2.42 | 4.12 | 13.05 | 18.24 | 21.14 | 22.44 |
| 26 | 2.43 | 4.13 | 13.05 | 18.24 | 21.14 | 22.44 |
| 27 | 2.43 | 4.13 | 13.05 | 18.24 | 21.14 | 22.44 |
| 28 | 2.44 | 4.14 | 13.05 | 18.24 | 21.14 | 22.44 |
| 29 | 2.44 | 4.14 | 13.05 | 18.24 | 21.14 | 22.44 |
| 30 | 2.45 | 4.15 | 13.05 | 18.24 | 21.13 | 22.43 |

*Намаз вакытлары турында мәгълүматларны Самара өлкәсе мөселманнарының Региональ Диния нәзарәте хезмәткәрләре әзерләде, мөфти Вагыйз хәзрәт ЯРУЛЛИН раслады. Җомга көннәре аерып күрсәтелгән.*

**Учредители: трудовой коллектив редакции газеты «Бердэмлек» и Региональное Духовное управление мусульман Самарской области.**

**Оештыручылар: «Бердәмлек» газетасы редакциясенең хезмәт коллективы һәм Самара өлкәсе мөселманнарының Региональ Диния нәзарәте.**

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

# Кыйбла

„БЕРДӘМЛЕК" ГАЗЕТАСЫНЫҢ АЙЛЫК ДИНИ КУШЫМТАСЫ

№ 5
2012 ел
май

№ 22 (1149), 26 май 2012 ел

*ВӘГАЗЬ*

## Кеше һәм күзгә күренмәүче затлар

Кешенең сиземләве җәһәтеннән яралтылган затларны, мәхлукларны күзгә күренүче һәм күзгә күренмәүче буларак икегә аерып карарга мөмкин. Коръән-Кәримдә кешедән тыш, Аллаһының хикмәтле рәвештә барлыкка китергән күзгә күренмәүче мәхлукларының да хәбәре бирелә. Болар - фәрештәләр, җеннәр һәм шайтаннар.

Ислам традициясендә фәрештәләргә ышану иман шартларының берсе итеп күрсәтелә. *"Пәйгамбәр Раббысы тарафыннан үзенә иңдерелгәнгә иман итте мөэминнәр дә. Һәрберсе Аллаһыга, фәрештәләренә, китапларына, пәйгамбәрләренә иман иттеләр",* – дип бу вәзгыять ачыклана.

Фәрештә илче, хәбәр китерүче, көч-куәт мәгънәсенә туры килә. Фәрештәләр күзгә күренмиләр. Алар даими рәвештә Аллаһыга гыйбадәт кылалар һәм аның әмерләрен җиренә җиткерәләр. Фәрештәләр гөнаһ эшләмәсләр, ашап-эчмәсләр, ачыкмаслар һәм ару-талуны белмәсләр. Аятьләрдә: *"Анда Аллаһыга беркайчан да каршы килмәүче, аның әмерләрен җиренә җиткерүче көчле фәрештәләр бар"*. *"Алар Раббыларыннан куркалар һәм үзләренә нинди әмер бирелсә, аны башкаралар". "Алар армый-талмый, көнне төнгә ялгап, Аллаһыга тәсбих әйтәләр",* диелә. Фәрештәләр төрле вазифалар башкаралар. Алар: *"Безнең барыбызның да төрле вазифаларыбыз бар",* - диләр.

Башкарган вазифаларына күрә фәрештәләрне төрле төркемнәргә бүлеп карарга була. Мәсәлән, 4 бөек фәрештә бар. Алардан Җәбраил - Аллаһының әмер һәм тыюларын пәйгамбәрләргә җиткерүче фәрештә. Аллаһы белән Пәйгамбәр арасындагы илче. Микаил - табигать эшләре белән идарә итүче һәм табигатьтәге ризык эшләре белән вазифалы фәрештә. Исрафил - кыямәт көнен кешеләргә белгертәчәк фәрештә. Сур исемле бер коралга өреп, дөнья тормышының беткәнен һәм кыямәт көненең башланганын белгертүче. Газраил - җан алучы фәрештә. Аллаһының әмере белән әҗәле җиткән кешеләрнең рухын алучы. Болардан тыш кешеләрне төрле каза һәм бәлаләрдән саклаучы хафаза фәрештәләре бар. Бу фәрештәләр Аллаһының рөхсәте белән кешеләргә ярдәмгә ашыгалар. Аятьләрдә: *"Шөбһәсез, Раббыбыз Аллаһыдыр дип тугры юлда булучыларга фәрештәләр иңдерелер. Кешеләргә: "Курыкмагыз, борчылмагыз, сезгә вәгъдә ителгән җәннәт белән сөенегез, – диярләр. "Без дөньяда да, ахирәттә дә сезнең дусларыгыз", – диелә".*

Шулай ук кешеләрнең яхшы-начар барлык гамәлләрен һәм тотышларын, кешеләрнең гөнаһ-савапларын язып баручы фәрештәләр дә бар. Боларны Кирамән Катибин фәрештәләре дип йөртәләр. Бу фәрештәләр кешеләрнең уң һәм сул җилкәләрендә булалар. Уң яктагысы - савапларны, сул яктагысы - гөнаһларны язып баручы. Мөнкәр һәм Нәкир фәрештәләре - үлгәннән соң кабергә күмелгән кешедән сорау алучы фәрештәләр.

Фәрештәләрдән тыш, күзгә күренмәүче затларның тагын берсе – җеннәр. Коръән-Кәримдә җеннәрнең уттан яралтылган булуы белдерелә. Җеннәр дә кешеләр кебек Аллаһыны тану, аңа гыйбадәт кылу өчен җаваплы. Коръән-Кәримдә: *"Мин җеннәрне һәм кешеләрне бары тик миңа гыйбадәтче булсыннар дип яралттым",* – диелә. Җеннәрнең һәм яхшылары, һәм начарлары бар. Начар кешеләрдән Аллаһыга сыенырга кирәк булган кебек, җеннәрнең дә начарларыннан һәм аларның начарлыкларыннан Аллаһыга сыену кирәк. Коръән-Кәримнең соңгы ике сүрәсе булган "Фәләкъ" һәм "Нәс" сүрәсе кешеләргә бу мәсьәләдә үгет-нәсыйхәт, киңәш бирә. Бу - бик мөһим мәсьәлә. Чөнки кайбер кешеләр эчләрендәге кызыксыну хисе белән алар хакында бик күп мәгълүматка ия булмаган мәхлуклар белән элемтәгә керү өчен төрле юлларга мөрәҗәгать итә. Фәкать кешеләрнең нәтиҗәдә һәм матди, һәм рухи яктан зур зыян күрүләре күзәтелә. Аллаһы кешеләрнең шартларын танымаган бу затлар белән бергә хезмәттәшлек кору мәсьәләсендә кисәтүләр ясый һәм моны тыя. Аллаһ әфсен, сихер